БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«16» 10 2025 ел

**КАРАР**
№ 292

2026 елга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирә торган мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирщ торган мәгариф учрежденияләрен норматив финанслауны кертү турында» 854 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирә торган мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны 1 нче кушымта нигезендә;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә коэффициентын 0,85 кә тигез итеп.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында http://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) һәм Татарстан Республикасы «Балтач район башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2025 елның «16» 10
292 номерлы карары нигезендә расланган
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирә торган мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | сигез еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | 99 826 | 95 524 | 96 798 | 111 416 | 115 995 | 150 794 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 49 900 | 42 477 | 39 295 | 43 367 | 99 300 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Бию сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 97 308 | 79 435 | 84 263 | 342 950 |
| Бию сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 43 534 | | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 101 217 | 97 465 | 100 551 | 165 858 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 156 530 | | 151 191 | | | 263 997 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 77 614 | 70 087 | 72 585 | 72 557 | 76 069 | 107 794 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |